**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№04**
**11.01.2021**

Яр Чаллы шәһәренең «Муниципаль заказ дирекциясе» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

Шәһәр Советының «Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары, Башкарма комитетның «Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Муниципаль заказ дирекциясе» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 11 гыйнварындагы
04 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
«Муниципаль заказ дирекциясе» муниципаль казна предприятиесе
тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/с | Хезмәтнең исеме | Бәя сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Сатып алулар өлкәсендәге законнар буенча юридик консультация бирү | 2163,27 |
| 2. | Документлар пакеты әзерләү һәм ЭТПда аккредитация алу буенча техник ярдәм күрсәтү | 4530,62 |
| 3. | ТР сатулар турында мәгълүмат мониторингы (эшчәнлек өлкәсе буенча тендерлар сайлап алу) | 3662,70 |
| 4. | Электрон аукцион буенча ярдәм күрсәтү (тәэмин итүчеләр өчен) | 5064,07 |
| 5. | Электрон сәүдә мәйданчыкларында тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү процедурасында ярдәм күрсәтү | 1377,24 |
| 6. | Сатуларда катнашуга заявка әзерләү (тәэмин итүчеләр өчен) | 5250,19 |
| 7. | ТР Федераль монополиягә каршы хезмәт идарәсенә гариза әзерләү | 5277,69 |
| 8. | ТР Федераль монополиягә каршы хезмәт идарәсендә, судларда мәнфәгатьләрне яклау | 15903,56 |
| 9. | Дәүләт яки муниципаль мөлкәтне арендалау, сату шартнамәсе төзү хокукына электрон аукцион үткәрү | 5204,35 |
| 10. | Аукцион процедурасы үткәрү | 856,27 |
| 11. | Дәүләт яки муниципаль мөлкәтне арендалау, сату шартнамәсе төзү хокукына ачык аукцион үткәрү (1 лот) | 9012,94 |
| 12. | Дәүләт яки муниципаль мөлкәтне арендалау, сату шартнамәсе төзү хокукына ачык аукцион үткәрү (2-6 лотлар) | 12633,09 |
| 13. | Дәүләт яки муниципаль мөлкәтне арендалау, сату шартнамәсе төзү хокукына ачык аукцион үткәрү (6 дан башлап һәм аннан күбрәк лот) | 15423,42 |
| 14. | Электрон формада конкурс яки аукцион үткәрү юлы белән тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү | 11892,87 |
| 15. | Сатып алу эшчәнлеге буенча юридик ярдәм (44-ФЗ номерлы, 223-ФЗ номерлы Федераль закон буенча) | 8210,09 |

Искәрмә: Б(М)Б – сатып алу гамәлгә ашырыла торган хокукка төзелгән контрактның (шартнамәнең) башлангыч (максималь) бәясе

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Бареева